# КАРАР

**20 ноябрь, 2025 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Княгор авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 20 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Княгор авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 85 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 49 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 47 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 2 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Княгор авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2026 елда Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Княгор авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокле хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар кабул иттек:

-- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

Карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Починок-Көчек авыл җирлеге башлыгы И. А. Йосыпов